РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАРЫ**

2020 елның «20» октябре 420№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 12 маендагы «Аренда түләүләрен түләүне
азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык
субъектларына ярдәм итү чаралары турында»
191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 1497-р номерлы Күрсәтмәсенә таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карар итте:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы «Аренда түләүләрен түләүне азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү чаралары турында» 191 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктта:

а) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) арендаторлар мөрәҗәгать иткән көннән алып 7 эш көне дәвамында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге "Яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары Исемлеген раслау турында» 434 номерлы карары белән расланган Россия икътисады тармаклары Исемлеге буенча бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы, яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начарлану шартларында иң күп зыян күргән, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларга кертелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар реестрындагы коммерциясез оешмалар белән муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен дә) арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр аренда түләүләрен кичектерүне күз алдында тотучы өстәмә килешүләр төзү.

Арендатор юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреле торышы буенча бирелә мәгълүматка карап, икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә.

Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага кадәр Татарстан Республикасы дәүләт казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча үтәлмәгән бурычы булмаган, күрсәтелгән икътисадый эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен аннан файдалану максатларында муниципаль мөлкәт (шул исәптән җир кишәрлекләре) арендага алуны күздә тотучы һәм эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне куллануны раслау турындагы документлары булган арендаторлар белән аренда шартнамәләренә өстәмә килешүләр төзелә.»;

- б) пунктчасында «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары» сүзләреннән соң, «социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар» сүзләрен өстәргә;

- 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктындагы а) пунктчасында күрсәтелгән арендага алучылар белән өстәмә килешүләр түбәндәге шартларда төзелә:

аренда түләве буенча бурыч арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән срокт, 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр күләмендә, айга бер тапкырдан да еш алынмыйча түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә аренда түләве буенча бурыч берьюлы түләнә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов